МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.11.2023 Казан ш. № 872од

«Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 14.02.2017 ел, № 132/1 од боерыгына 1 нче Кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРАМ:

1. «Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 14.02.2017 ел, № 132/1 ОД боерыгына 1 нче Кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, шәһәр зираты адресы буенча урнашкан «Зират часовнясы, XIX гасырның 2нче яртысы» җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территорияләре чикләре картасы (схема) үз көчен югалткан дип танырга;

Алабуга шәһәре, шәһәр зираты адресы буенча урнашкан «Зират часовнясы, XIX гасырның 2нче яртысы» җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картографик тасвирламасы үз көчен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, шәһәр зираты адресы буенча урнашкан «Зират часовнясы, XIX гасырның 2нче яртысы» җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чигенең борылыш нокталары таблицасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлегенә дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына боерык җибәрергә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Министр вазифаларын
башкаручы ............................ Ю.И.Әдһәмова